ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.02.2021 ел Баулы шәһәре №7

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 12 августындагы 260 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү тәртибенә өстәмә кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге «Субсидияләр бирүне, шул исәптән юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым бүлекләре үз көчен югалтуын тану турында» 1492 номерлы карары нигезендә, 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылык идарәсенең, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясенең ПР-3 беркетмәсен үтәү өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 12 августындагы 260 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6нчы пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка

түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә.»;

8нче пунктның икенче абзацында «2нче һәм 5нче пункт шартларына» сүзләрен «2нче, 4нче, 5нче һәм 6нчы» сүзләренә алмаштырырга;

8нче пунктның дүртенче абзацында «2нче һәм 5нче пункт шартларына» сүзләрен «2нче, 4нче, 5нче һәм 6нчы пункт шартларына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Л.С. Свежинкинага йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе                                        И.И. Гозәеров